РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.04.2019 № 55-п

«Минем шәҗәрәм» республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү турында

Нәсел традицияләрен саклап калу һәм үстерү, гаилә элемтәләрен һәм буыннар бәйләнешен ныгыту, Татарстан һәм гаиләң тарихына карата кызыксынуны үстерү, тарихи аң формалаштыру һәм ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү, шулай ук архив материаллары белән эшләүгә, тарихи әдәбият һәм туган якны өйрәнү буенча әдәбият укуга җәлеп итү һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсы турында” 19.02.2019 31-од номерлы боерыгын үтәү максатыннан,

КАРАР БИРӘМ:

1. Саба муниципаль районында «Минем шәҗәрәм» республика конкурсының муниципаль этабын үткәрергә.

2. 2019 елда «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабы турында Нигезләмәне расларга (теркәлә).

3. «Минем шәҗәрәм» республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү буенча оештыру комитеты составын расларга (теркәлә).

4. Авыл җирлекләре башлыкларына, идарә һәм бүлек начальникларына, гомуми белем бирү учреждениеләре, шулай ук урта һәм урта һөнәри белем учреждениеләре директорларына, иҗтимагый оешмалар җитәкчеләренә «Минем шәҗәрәм» конкурсының муниципаль этабында катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты җитәкчесе М.Р. Кәримовка йөкләргә.

Р.Н. Минниханов

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башлыгының
02.04. 2019 ел 55-п номерлы
карары белән

2019 елда «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабы турында Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2019 елда «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү турында әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, конкурс) конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибен, конкурс эшләрен бәяләү критерийларын билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет).

1.4. Конкурс 2019 елның 20 мартыннан 15 апрелен кертеп үткәрелә.

## II. Конкурсның максаты һәм бурычлары

2.1. Конкурсның төп максаты булып гаилә шәҗәрәсе традицияләрен торгызу, гаилә кыйммәтләрен саклауга ярдәм итү тора.

2.2. Конкурсның бурычлары:

шәҗәрә традицияләрен саклау һәм үстерү;

гаилә тарихының ил һәм туган як тарихына катнашын өйрәнү нигезендә балалар һәм яшьләрне ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләүгә булышлык күрсәтү;

гаилә традицияләрен һәм буыннар арасындагы элемтәләрне ныгытуга ярдәм итү;

тарихи-шәҗәрә тикшеренүләре традицияләрен саклау һәм үстерү;

архив материаллары белән эшләүгә, тарихи әдәбият һәм туган якны өйрәнү буенча әдәбиятне укуга җәлеп итү.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста дүрт яшь төркеме буенча теләгән һәркем катнаша ала:

1 төркем – гомуми белем бирү учреждениеләренең 1-4 сыйныф укучылары;

2 группа – гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-8 сыйныф укучылары;

3 группа – гомуми белем бирү учреждениеләренең 9-11 сыйныф укучылары;

4 группа – 18 яшькә кадәрге һөнәри белем бирү учреждениеләре укучылары.

3.2. Конкурста җиңүчеләр һәр яшь төркеме буенча аерым билгеләнә.

3.3. 16 яшьтән яшьрәк булган конкурста катнашучы гаризасына катнашучының ата-анасының берсе (яки законлы вәкил) имза.

3.4. Конкурска, 1 нче яшь төркемендә катнашучылардан тыш, бары тик индивидуаль тәртиптә башкарылган эшләр генә кабул ителә.

## IV. Конкурсның оештыру комитеты

4.1. Конкурсны оештыру, үткәрү һәм нәтиҗәләр ясау өчен рәисе, рәис урынбасары һәм оештыру комитеты әгъзалары составында җиде кешедән торган оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә.

4.2. Оештыру комитетының функцияләре:

бәйгене әзерләү һәм үткәрүне оештыруны тәэмин итү;

конкурс гаризаларын җыю;

конкурс барышы турында массакүләм мәгълүмат чараларында, Саба муниципаль районы сайтында хәбәр итү;

оештыру комитеты утырышы беркетмәләре нигезендә җиңүчеләр исемлеген формалаштыру.

4.3. Утырышта оештыру комитеты әгъзаларының гомуми саныннан күпчелеге катнашса, утырышлар тулы хокуклы санала.

## V. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

5.1. Муниципаль этаптта конкурста катнашу өчен гаризаны электрон рәвештә һәм/яки кулга тапшырырга, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты архив бүлеге адресына почта аша җибәрергә кирәк.

5.2. Конкурс материаллары яшь төркемнәренә туры китереп түбәндәге форматларда тапшырыла:

1 төркем – иҗади эш (нәсел агачы рәсеме, аңлатмалар белән фотоальбомнар, коллажлар, схемалар, плакатлар, аппликация, табигый материал һәм тукыма файдаланып күләмле эш һ.б.). Бер катнашучыдан эш саны чикләнми;

2 төркем – иҗади эш (нәсел агачы рәсеме, аңлатмалар белән фотоальбомнар, коллажлар, схемалар, плакатлар, аппликация, табигый материал һәм тукыма файдаланып күләмле эш) һәм А4 форматында 14 үлчәмле Times New Roman шрифты белән башкарылган, сул як кыры – 2 см, уң як кыры – 1,5 см, өске һәм аскы кырлары – 2 см булган (битләрне номерлау мәҗбүри) 10 биткә кадәр язма эш (реферат, эссе, инша һ.б.). Кушымталар күләме чикләнми;

3 төркем – теләсә кайсы форматта башкарылган тикшеренү эше (язма эш (А4 форматында 14 үлчәмле Times New Roman шрифты белән башкарылган, сул як кыры – 2 см, уң як кыры – 1,5 см, өске һәм аскы кырлары - 2 см (битләрнең нумерациясе мәҗбүри) 15 биткә кадәр аналитик хисап), видеоэшләр (гаилә тарихы турында фильмнар (10 минутка кадәр), Microsoft Power Point форматында презентация (50 слайдка кадәр);

4 төркем – архив документлары нигезендә проект-тикшеренү эше (фәнни хисап, фәнни мәкалә, доклад);

видеоэшләр – гаилә тарихы турында фильмнар (дәвамлыгы 60 минутка кадәр);

Microsoft Power Point форматында презентацияләр (50гә кадәр слайдлар).

5.3. Конкурска җибәрелгән эшләр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

5.4. Конкурска материаллар тәкъдим итү, авторлык хокукларын саклаганда, аларны конкурсны оештыручының чараларында куллануга авторның ризалыгын аңлата.

5.5. Җибәрелгән материаллар, авторның(ларның) ризалыгы белән Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүмат системасына йөкләү өчен файдаланылырга мөмкин.

Присланные материалы с согласия автора(ов) могут быть использованы для загрузки в Единую архивную информационную систему Республики Татарстан.

5.6. Документларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң җибәрелгән материаллар каралмый.

## VI. Конкурс эшләренә карата таләпләр

6.1. 1-4 яшь төркем конкурста катнашучыларның конкурс эшләренә карата таләпләр:

эшнең максатлары һәм бурычлары булу;

үз нәселе тарихы турында нигезле һәм документаль расланган мәгълүмат булу, архив документларына сылтамалар булу, бирелгән материаллардагы мәгълүматларга ышандыру өчен кирәкле аңлатма язулары һәм тарихи белешмәләр;

ата-бабаларының тормыш эшчәнлеге, аларның ил, туган як тарихында роле турында мәгълүматлар булу (бу мәгълүмат булган очракта);

үз гаиләсенең милли тамырлары һәм ата-бабаларының дине турында мәгълүматлар булу (бу мәгълүмат булган очракта).

Эштә документлар белән расланган мәгълүматлар гына түгел, гаилә тарихындагы документлар белән раслау мөмкин булмаган теләсә нинди кызыклы фактлар да тәкъдим ителергә мөмкин. Аудиофайл яки киңәйтелгән текст рәвешендә тәкъдим ителгән әңгәмәләр, истәлекләр һәм интервью материалларын куллану рөхсәт ителә.

Булган очракта ата-бабаларының, шул исәптән хезмәт ветераннарының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, иҗтимагый һәм һөнәри эшчәнлеге турында мәгълүматлар тәкъдим ителергә мөмкин.

6.2. Эшләр рус һәм (яки) татар телләрендә бирелә.

## VII. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

7.1. 1 төркемнең эшләрен бәяләү критерийлары:

конкурсның максатлары һәм бурычларына туры килү (0 дән 10 баллга кадәр);

эшне рәсмиләштерүдә үзенчәлеклек һәм иҗади якын килү (0 дән 10 баллга кадәр));

идеяне техник гамәлгә ашыру дәрәҗәсе (0 дән 10 баллга кадәр);

конкурс эшен әзерләүдә мөстәкыйльлек дәрәҗәсе (0 дән 10 баллга кадәр);

китерелгән тарихи фактларның дөреслеге (0 дән 10 баллга кадәр).

7.2. 2-3 төркемнең эшләрен бәяләү критерийлары

конкурсның максаты һәм бурычларына туры килү (0 дән 10 баллга кадәр);

китерелгән тарихи фактларның дөреслеге, архив чыганакларыннан файдалану дәрәҗәсе (0 дән 10 баллга кадәр);

гаилә кыйммәтләрен һәм гореф-гадәтләрен ачу дәрәҗәсе (0 дән 10 баллга кадәр);

үз нәселен өйрәнү-тикшеренүнең тирәнлеге (0 дән 10 баллга кадәр);

үз фамилиясенең килеп чыгышы турында, милли тамырлары, ата-бабаларының дине турында мәгълүматларның булуы һәм нигезлелеге (0 дән 10 баллга кадәр);

ил һәм туган як тарихында һәм тормышында нәсел вәкилләренең роле турында белем тирәнлеге (0 дән 10 баллга кадәр);

эшнең сәнгать дәрәҗәсе (әдәби тел, бәян ителүнең образлылыгы, тәкъдим ителгән материалны рәсмиләштерү сыйфаты) (0 дән 10 баллга кадәр));

кулланылган тарихи чыганакларның төрлелеге (документлар, хатлар, гаилә риваятьләре һ.б.) (0 дән 10 баллга кадәр).

7.3. 4 төркемнең эшләрен бәяләү критерийлары:

фамилиясенең килеп чыгышы, милли тамырлары, ата-бабаларының дине, аларның тормыш эшчәнлеге турында нигезле белешмәләрне кертеп, проблеманы өйрәнү тирәнлеге, (0 дән 10 баллга кадәр);

авторитетлы чыганакларга сылтамалар һәм үз нәтиҗәләре белән тарихи мәгълүматларны анализлау тирәнлеге (0 дән 10 баллга кадәр);

файдалану мөмкинлеге булган барлык төп архив чыганакларын колачлау, файдаланылган әдәбиятның зур күләме (0 дән 10 баллга кадәр);

структура төгәллеге һәм материалны бәян итү эзлеклелеге (0 дән 10 баллга кадәр);

эшнең гамәли һәм фәнни әһәмияте (0 дән 10 баллга кадәр).

## VIII. Җиңүчеләрне билгеләү тәртибе, нәтиҗәләр ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

8.1. Документлар пакеты тапшырылып беткәннән соң оештыру комитеты утырышы уздырыла (2019 елның 17 апреле).

8.2. Конкурста җиңүчеләр исемлеге катнашучыларның йомгаклау рейтингы нигезендә һәр яшь төркеме буенча аерым төзелә.

8.3. Конкурс нәтиҗәләре буенча яшь төркемнәре чикләрендә рейтингта беренче өч урынны алган катнашучылар конкурста җиңүчеләр дип танылa.

8.4. Конкурста катнашу өчен документлар пакеты һәм эшләр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегенә Saby.arhiv@tatar.ru электрон почтасы адресына яки кулга 2019 елның 12 апреленә кадәр тапшырыла:

- № 1 кушымтада күрсәтелгән форма буенча гариза;
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (2 нче кушымта);
- конкурс материаллары комплекты.

8.5. Конкурста җиңүчеләр конкурс дипломнары һәм призлар белән бүләкләнә.

2019 елда «Минем шәҗәрәм»
генеалогик тикшеренүләр
республика конкурсының
муниципаль этабы турында
Нигезләмәгә
1 нче кушымта

2019 елда «Минем шәҗәрәм " генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабында катнашу өчен гариза

| | |
|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Катнашучының яше | |
| Катнашучы белем ала торган белем бирү оешмасы; катнашучының эш урыны | |
| Катнашучының индекс белән тулы өй адрес | |
| Катнашучының элемтә өчен телефоннары | |
| Катнашучы электрон почтасы | |
| Конкурс эшенең исеме | |
| Эш тәкъдим ителгән яшь төркеме | |

2019 елда «Минем шәҗәрәм»
генеалогик тикшеренүләр
республика конкурсының
муниципаль этабы турында
Нигезләмәгә
2 нче кушымта

шәхси мәгълүматларны эшкәртү, тапшыру һәм таратуга ризалык

2019 елда «Минем шәҗәрәм» республика генеалогик тикшеренүләр бәйгесен оештыручыга «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, минем шәхси мәгълүматларын эшкәртү, тапшыру һәм таратуга (шул исәптән аларны миннән һәм/яки теләсә нинди өченче затлардан алуны да кертеп) түбәндәгн күләмдә риза:

Эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге (Ф. И.А.И. (соңгысы – булган очракта)), җенес, туу датасы һәм урыны, гражданлыгы, шәхесне раслаучы документ реквизитлары (документ төре, аның сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән мобиль), электрон почта адресы)

________________________________________________________________

(Ф. И. А.И. (соңгысы - булган очракта), имза)

____________________

(дата)

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башлыгының
02.04. 2019 ел 55-п номерлы
карары белән

«Минем шәҗәрәм» республика конкурсының муниципаль этабын
үткәрү буенча оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Кәримов М.Р. | Заместитель Руководителя Исполнительного комитета - Руководитель аппарата Исполнительного комитета Сабинского муниципального района Республики Татарстан, председатель комиссии |
| Сиражетдинова А.Н. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге начальнигы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Шәфыйкова Г.И. | “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе начальнигының тәрбия эшләре буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Закирова И.Н. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге баш белгече, комиссия сәркатибе; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Шәйхетдинова А.И. | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты ГХАТ бүлеге начальнигы; |
| Бикмөхәммәтов З.М. | «Саба аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча); |
| Мортазин Н.В. | «Минем гаилә агачы» сайтына нигез салучы (килешү буенча); |
| Мөбәрәкова Ә.Г. | «Татмедиа» АҖ филиалы «Саба дулкыннары» ТРК җитәкчесе (килешү буенча); |
| Исмәгыйлов Р.Г. | «Татмедиа» АҖ филиалы «Саба Таннары» газетасы редакциясе җитәкчесе (килешү буенча); |